5.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең хезмәт өчен түләүнең расланган фонды чикләрендә тиешле финанс елына һәм хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

5.3. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{sd}$)аерым муниципаль учреждениеләрдә фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ - эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме 4 нче таблицада китерелгән.

5.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге сайланулы профсоюз органы (яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган) белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

4 нче таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен тәкъдим ителә торган өстәмә түләүләр күләме**

| N т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрне билгеләү нигезләре | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Региональ әһәмияттәге мәдәният учреждениеләрендә эш | 1 | 20 |
| | | 2 | 25 |
| | | 3 | 30 |
| | | 4 | 40 |
| 2. | Региональ әһәмияттәге мәдәният учреждениеләрендә гамәли эштә ике дәүләт телен куллану | 1 - 4 | 10 |

5.5. Хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус шартлары булган эшләрдә эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә компенсация характерын түләү ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$O_d$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең төп оклады;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләргә өстәмәләр күләме;

$H_{fk}$ - законнар нигезендә компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_n$- Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эш хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгать нормасы.

Хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч шартлары булган эшләрдә эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

5.6. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

Зеленодольск муниципаль районы
муниципаль мәдәният учреждениеләренең
фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр
өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының
һөнәри квалификация төркемнәре
хезмәткәрләренең хезмәте өчен
түләү шартлары турындагы нигезләмәгә
кушымта

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ СОСТАВЫНДАГЫ СОЮЗДАШ ҺӘМ АВТОНОМИЯЛЕ РЕСПУБЛИКАЛАРНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ БУЛГАН ӨЧЕН СТИМУЛЛАШТЫРУ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР БИРЕЛӘ ТОРГАН ИСЕМЛЕК**

| N т/б | Мактаулы исем, дәүләт бүләге атамасы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 2.3. | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.2. | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.3. | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |

| | |
|---|---|
| 4.2. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.3. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.5. | Атказанган фән эшлеклесе |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 07 апрелендәге
1210 номерлы карарына
4 нче кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ МӘДӘНИЯТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНЕҢ МӘДӘНИЯТ,СӘНГАТЬ, КИНЕМАТОГРАФИЯ ЭШЧЕ ҺӨНӘРЛӘРЕНЕҢ ҺӨНӘРИ КВАЛИФИКАЦИЯ ТӨРКЕМНӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТЕ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать, кинематография эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә (алга таба-Нигезләмә, мәдәният эшчеләре) окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын гамәлгә кертә.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы - федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән база окладларын, окладлар күләмен, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне ,мәдәният эшчеләренең хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады - компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы һөнәре буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы мәдәният эшчесенең оклады;

вазыйфаи оклад – ставканы исәпкә алып, календарь айда билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүнең, компенсация, стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, билгеләнгән күләме;

хезмәткәрнең эш хакы (хезмәте өчен түләү) - мәдәният эшчесенең квалификациясенә, катлаулылыгына, башкарыла торган эшнең сыйфатына һәм шартларына, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләренә бәйле рәвештә хезмәте өчен түләү;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән эш өчен компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

1.3. Мәдәният эшчесенең эш хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

окладлардан (вазыйфаи окладларыннан), эш хакы ставкаларыннан;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

компенсация характерындагы түләүләрдән.

## II. Мәдәният эшчеләренең база окладларын билгеләү

2.1. Мәдәният эшчеләренең  база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|
| "Беренче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| "Икенче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 010 |

Эшче һөнәрләрен мәдәният эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре квалификация дәрәҗәләренә кертү

| N т/б | Мәдәният эшчеләре һөнәрләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| "Беренче дәрәҗәдәге мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләре" профессиональ квалификация төркеме | |
| 1.1. | Клавиш инструментлары детальләрен әзерләү автоматчысы |
| 1.2. | Телле инструментлар арматурщигы |
| 1.3. | Чиртмә инструментлар аэрографисты |
| 1.4. | Бутафорчы |
| 1.5. | Музыкаль уен коралларын көйләүче (гарнировщик) |
| 1.6. | Мех камераларын бермәләүче (гофрировщик) |

| | |
|---|---|
| 1.7. | Гример-постижер |
| 1.8. | Уен автоматларының, аттракционнарның һәм тирның дежур торучысы |
| 1.9. | Тавыш планкаларын тоташтыручы (заливщик) |
| 1.10. | Тавыш планкаларын ясаучы |
| 1.11. | Тынлы уен кораллары өчен детальләр әзерләүче |
| 1.12. | Субтитрлар әзерләүче |
| 1.13. | Киномеханик |
| 1.14. | Клавиатурчы |
| 1.15. | Бизәүче (Колорист) |
| 1.16. | Музыкаль инструментлар детальләрен комплектлаучы |
| 1.17. | Контурчы |
| 1.18. | Костюмер |
| 1.19. | Декорацияләр бизәлеше буенча маляр |
| 1.20. | Сәхнә машинисты |
| 1.21. | Негатив монтажлаучы |
| 1.22. | Позитив монтажлаучы |
| 1.23. | Сәхнә монтажчысы |
| 1.24. | Перламутр эшкәртүче |
| 1.25. | Магнит язмасы операторы |
| 1.26. | Клавишлы уен коралларын уйнату стенды операторы |
| 1.27. | Яктыртучы |
| 1.28. | Дипозитив фильмнарны ясаучы |
| 1.29. | Субтитр бастыручы |
| 1.30. | Пиротехник |
| 1.31. | Мультипликацион рәсемнәр өчен нигез әзерләүче |
| 1.32. | Музыка уен коралларын шомартучы (полировщик) |
| 1.33. | Постижер |
| 1.34. | Фильерларны таратучы (расшлифовщик) |
| 1.35. | Реквизитор |

| | |
|---|---|
| 1.36. | Субтитрлар эшкәртүче (ретушер) |
| 1.37. | Тынлы уен коралларын жыючы |
| 1.38. | Бәрмә уен коралларын җыючы |
| 1.39. | Телле уен коралларын җыючы |
| 1.40. | Клавишлы уен коралларын җыючы -монтажчы |
| 1.41. | Сызгычлы (Смычковые) уен коралларын җыючы -монтажчы |
| 1.42. | Чиртмәле  уен коралларын жыючы -монтажчы |
| 1.43. | Махсус агач эшкәртү станоклары станокчысы |
| 1.44. | Махсус металл эшкәртү станоклары станокчысы |
| 1.45. | Декорацияләр әзерләү буенча столяр |
| 1.46. | Музыкаль уен коралллары детальләрен һәм төеннәрен әзерләү һәм ремонтлау столяры |
| 1.47. | Кыл ураучы (струнонавивальщик) |
| 1.48. | Кылчы (струнщик) |
| 1.49. | Мультипликацион сынап карауларны төшерүче |
| 1.50. | Дипозитив фильмнар төшерүче (укладчик) |
| 1.51. | Униформист |
| 1.52. | Декорацияләр куючы |
| 1.53. | Тел тәлинкәләрен урнаштыручы |
| 1.54. | Фильмнарны тикшерүче |
| 1.55. | Фильмотекарь |
| 1.56. | Фототекарь |
| "Икенче дәрәҗәдәге мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләре" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.1.1. | Клавишлы уен кораллары рамын бронзалаучы |
| 2.1.2. | Видеотекарь |
| 2.1.3. | Уен курчакларын ясаучы |
| 2.1.4. | Клавишлы уен кораллары өчен чүкечләр ясаучы |
| 2.1.5. | Музыкаль уен кораллары контроле |

| | |
|---|---|
| 2.1.6. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.1.7. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.8. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.9. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.10. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.11. | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.12. | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.13. | Пианино һәм рояльләрне көйләүче |
| 2.1.14. | Чиртмәле уен коралларын көйләүче (настройщик) |
| 2.1.15. | Телле уен коралларын көйләүче |
| 2.1.16. | Видеоязма операторы |
| 2.1.17. | Киноҗайланма белән идарә итү пульты операторы |
| 2.1.18. | Пионино һәм рояль көйләүче (регулировщик) |
| 2.1.19. | Телле уен кораллары көйләүче (регулировщик) |
| 2.1.20. | Клавишлы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.21. | Бәрмә уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.22. | Фильмнарның күчермәләрен реставрацияләүче |
| 2.1.23. | Чиртмәле һәм сызгычлы (смычковые) уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.24. | Телле уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.1.25. | Фонотека белән эшләүче |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.2.1. | Уен курчакларын ясаучы |
| 2.2.2. | Индивидуаль заказлар буенча музыка кораллары әзерләүче |
| 2.2.3. | Интонировщик |
| 2.2.4. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.2.5. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.6. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.7. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |

| | |
|---|---|
| 2.2.8. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.9. | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.10. | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.11. | Тынлы уен коралларын көйләүче |
| 2.2.12. | Сызгычлы (смычковые) уен коралларын көйләүче (настройщик-регулировщик) |
| 2.2.13. | Видеоязма операторы |
| 2.2.14. | Тынлы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.2.15. | Фильмнарның күчермәләрен реставрацияләүче |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.3.1. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.2. | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.3. | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.4. | Видеоязма операторы |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Беренче - өченче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән, мөһим (аеруча мөһим) һәм җаваплы (аеруча җаваплы) эшләр башкаручы эшче һөнәрләре | |
| 2.4.1. | Уен курчакларын ясаучы |
| 2.4.2. | Индивидуаль заказлар буенча музыка кораллары әзерләүче |
| 2.4.3. | Интонировщик |
| 2.4.4. | Музыкаль уен кораллары контроле |
| 2.4.5. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.4.6. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.7. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.8. | Кинотелевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.9. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.10. | Телевидение җиһазларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.11. | Кинотехнология җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |

| | |
|---|---|
| 2.4.12. | Тынлы уен коралларын көйләүче |
| 2.4.13. | Пианино һәм рояльләрне көйләүче |
| 2.4.14. | Чиртмәле уен коралларын көйләүче (настройщик) |
| 2.4.15. | Телле уен коралларын көйләүче |
| 2.4.16. | Сызгычлы (смычковые) уен коралларын көйләүче (настройщик-регулировщик) |
| 2.4.17. | Видеоязма операторы |
| 2.4.18. | Пионино һәм рояль көйләүче (регулировщик) |
| 2.4.19. | Тынлы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.20. | Клавишлы уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.21. | Бәрмә уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.22. | Фильмнарның күчермәләрен реставрацияләүче |
| 2.4.23. | Чиртмәле  һәм сызгычлы (смычковые) уен коралларын реставрацияләүче |
| 2.4.24. | Телле уен коралларын реставрацияләүче |

2.2. Берьюлы берничә вазыйфа башкаручы мәдәният эшчеләренә, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында хезмәт өчен түләү, эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә башкарылган эш күләменнән чыгып башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы  берничә эшне бергә алып бару тәртибендә биләгән вазыйфа буенча эш хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла.

## III. Мәдәният эшчеләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

3.1. Мәдәният эшчеләренең вазыйфаи окладлары($O_d$)  түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган мәдәният эшчеләренең база оклады күләме;

$H_f$-мәдәният эшчеләре хезмәткәрләре өчен билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы цикләрендә эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_n$ - мәдәният эшчеләренең хезмәт хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгатьләр нормасы (хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакытының дәвамлылыгы).

## IV. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләрен стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

мактаулы исемнәр булган өчен түләү;

премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - мәдәният эшчеләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

4.5. Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзы составында союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге, әлеге Нигезләмәгә кушымтада китерелгән.

4.6. Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемгә ия булган мәдәният эшчеләренә мактаулы исемнәр булган өчен түләү, хезмәткәрнең сайлавы буенча мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

4.7. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр мәдәният эшчеләренә юбилей даталары, аерым хөрмәтләү билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, бүләкләр алу белән бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр башкарыла.

4.8. Премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләрне башкару күләме, тәртибе һәм шартлары Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.9. Мәдәният эшчеләренә премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме окладлар (эш хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) һәм хезмәткәрләргә төп вазыйфасы һәм төп эш урыны буенча

стимуллаштыру характерындагы түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

4.10. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенчамәдәният эшчеләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү рәвешендге түләү бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.11. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләрне башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениеләренең локаль актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

## V. Компенсация характерындагы түләүләр

5.1. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче мәдәният эшчеләренә түләүләр;

нормадан тайпылган шартларда эшләгән өчен түләүләр (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) бергә үтәгәндә, эш сәгатеннән тыш, төнлә эшләгәндә һәм һәм нормадан тайпыла торган башка шартларда эшләр башкарганда).

5.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең хезмәт өчен түләүнең расланган фонды чикләрендә тиешле финанс елына һәм хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

5.3. Хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус шартлары булган эшләрдә эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган мәдәният эшчесенең база оклады;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләргә өстәмәләр күләме;

$H_{fk}$ - законнар нигезендә компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_n$ - Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган мәдәният эшчеләренең эш хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгать нормасы.

Хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч шартлары булган эшләрдә эшләүче мәдәният эшчеләренең хезмәте өчен компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

5.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

Зеленодольск муниципаль районы
мәдәният муниципаль учреждениеләренең
мәдәният, сәнгать һәм кинематография
эшче һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре
хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары
турындагы нигезләмәгә
кушымта

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ СОСТАВЫНДАГЫ СОЮЗДАШ ҺӘМ АВТОНОМИЯЛЕ РЕСПУБЛИКАЛАРНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ БУЛГАН ӨЧЕН СТИМУЛЛАШТЫРУ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР БИРЕЛӘ ТОРГАН ИСЕМЛЕК**

| N т/б | Мактаулы исем, дәүләт бүләге атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган уйлап табучысы |
| 1.5. | Россия Федерациясенең Атказанган конструкторы |
| 1.6. | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.7. | Россия Федерациясенең Атказанган рационализаторы |
| 1.8. | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.5. | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.6. | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7. | Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы |
| 2.8. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |

| | |
|---|---|
| 2.9. | Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы |
| 2.10. | Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның Халык артисты |
| 3.2. | СССРның Халык рәссамы |
| 3.3. | СССРның Атказанган уйлап табучысы |
| 3.4. | СССРның Атказанган төзүчесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган полиграфчы |
| 4.2. | Атказанган пропагандачы |
| 4.3. | Халык артисты |
| 4.4. | Атказанган артист |
| 4.5. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.6. | Халык рәссамы |
| 4.7. | Атказанган рәссам |
| 4.8. | Халык язучысы |
| 4.9. | Атказанган язучы |
| 4.10. | Халык шагыйре |
| 4.11. | Халык җырчысы |
| 4.12. | Халык акыны |
| 4.13. | Атказанган журналист |
| 4.14. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.15. | Атказанган мәдәни-агарту эшләре хезмәткәре |
| 4.16. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.17. | Атказанган китапханәче |
| 4.18. | Атказанган келәмче |
| 4.19. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.20. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.21. | Атказанган фән эшлеклесе |

| | |
|---|---|
| 4.22. | Атказанган инженер |
| 4.23. | Атказанган уйлап табучы |
| 4.24. | Атказанган рационализатор |
| 4.25. | Атказанган оста |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган төзүче |
| 5.2. | Халык артисты |
| 5.3. | Атказанган артист |
| 5.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5. | Халык рәссамы |
| 5.6. | Атказанган рәссам |
| 5.7. | Халык язучысы |
| 5.8. | Атказанган язучы |
| 5.9. | Халык шагыйре |
| 5.10. | Атказанган журналист |
| 5.11. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 07 апрелендәге
1210 номерлы карарына
5 нче кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МӘДӘНИЯТ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНЕҢ ЭШЧЕЛӘР ГОМУМТАРМАК ҺӨНӘРЛӘРЕ, ҖИТӘКЧЕЛӘР, БЕЛГЕЧЛӘР ҺӘМ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ГОМУМТАРМАК ВАЗЫЙФАЛАРЫ ҺӨНӘРИ КВАЛИФИКАЦИЯСЕ ТӨРКЕМНӘРЕНӘ КЕРҮЧЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ХЕЗМӘТЕ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын гамәлгә кертә.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәткә түләү системасы - учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, база окладларын, вазыйфаи окладлар күләмнәрен, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне кертеп, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән нормалар җыелмасы;

база оклады - компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, эшче һөнәре яисә тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы учреждение хезмәткәренең оклады;

вазыйфаи оклад – ставканы исәпкә алып, календарь айда билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүнең, компенсация, стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, билгеләнгән күләме;

эш хакы (хезмәткәрнең хезмәт хакы) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм эшнең шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән эш өчен компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

1.3. Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең эш хакы түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

окладлардан (вазыйфаи окладларыннан), эш хакы ставкаларыннан;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

компенсация характерындагы түләүләрдән.

## II. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең эшче гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең эшче гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|
| "Беренче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| "Икенче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 010 |

2.2. Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| "Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |

| "Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 26 660 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 26 870 |
| "Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 27 080 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 27 300 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 27 560 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 780 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 28 000 |
| "Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 29 040 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 29 260 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 29 480 |

2.3. Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәре вазыйфасының һәм һөнәренең тиешле квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Берьюлы берничә эш башкаручы хезмәткәрләргә, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында хезмәт өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә эшләнгән эш күләменнән чыгып башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы берничә эшне бергә алып бару тәртибендә биләгән вазыйфа буенча эш хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла.

**III. Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләре эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомуми тармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе**

3.1. Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләре эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомуми тармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфаи

оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләре эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомуми тармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре база окладлы күләме;

$H_f$-Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең эш вакыты хезмәткәре өчен билгеләнгән чикләрдә эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_n$- Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең эш хакының база ставкасы (база окладлы) өчен сәгатьләр нормасы (хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакытының дәвамлылыгы).

## IV. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләрен стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

мактаулы исемнәр булган өчен түләү;

вазыйфасы буенча эш стажы өчен түләүләр;

премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр $_{pz}$) эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләре эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомуми тармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфаи окладлы;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

4.5. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада китерелгән.

4.6. Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре булган хезмәткәрләргә, мактаулы исемнәре булган өчен түләү, хезмәткәрнең сайлавы буенча мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

4.7. Вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләүләр($B_S$), вазыйфа (белгечлек) буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стаж төркемнәре буенча җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_S$ - эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

4.8. Вазыйфа буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмен түбәндәгеләр тәшкил итә:

вазыйфасы буенча эш стажы 2 елдан 5 елга кадәр булганда - 2,5 процент;

вазыйфасы буенча эш стажы 5 елдан 10 елга кадәр булганда - 4 процент;

вазыйфасы буенча эш стажы 10 елдан 15 елга кадәр булганда - 5 процент;

вазыйфасы буенча эш стажы 15 елдан артык булганда - 6 процент.

4.9. Эш стажы үзгәргәндә вазыйфа буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү)вазыйфа буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән, стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

4.10. Вазыйфа буенча эш стажына 1 нче таблица нигезендә вазыйфалар (һөнәрләр) буенча эшләү вакыты исәпләнә.

1 нче таблица

**Эш вакыты вазыйфасы буенча эш стажына кертелгән вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге**

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары («баш», «өлкән» вазыйфаи исемнәрен кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләр) исеме | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен белгечлек буенча эшләү чорлары эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш хисапчы урынбасары, хисапчы, хисапчы-ревизор, икътисадчы, хуҗалык эшчәнлеген анализлау һәм бухгалтер исәбе буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәпләү) үзәге икътисадчысы, килешү һәм дәгъвалар эше буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, кассир, таксировщик | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш хисапчы урынбасары, хисапчы, хисапчы-ревизор, икътисадчы, хуҗалык эшчәнлеген анализлау һәм бухгалтер исәбе буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәпләү) үзәге икътисадчысы, килешү һәм претензия эше буенча икътисадчы, матди-техник тәэмин итү икътисадчысы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, хезмәт буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, кассир, таксировщик |
| 2. | Материал-техник тәэмин итү буенча икътисадчы | Материал-техник тәэмин итү буенча икътисадчы,матди-техник тәэминат бүлеге башлыгы, склад мөдире, хисапчы, хисапчы-ревизор, икътисадчы, хуҗалык эшчәнлеген анализлау һәм бухгалтер исәбе буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәпләү) үзәге икътисадчы, килешү һәм дәгъвалар эшләре буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, финанс эшләре буенча икътисадчы,таксировщик, учетчик |
| 3. | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюро) башлыгы, хезмәт буенча | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү |

| | | |
|---|---|---|
| | норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюро) башлыгы, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер , хезмәтне оештыру буенча инженер, хезмәт буенча техник, нарядчик, хронометражчы | лабораториясе башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, социаль үсеш бүлеге башлыгы, хезмәт буенча икътисадчы, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, инструктор-дактилолог, хезмәт буенча техник, социолог, нарядчы, хронометражист |
| 4. | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча инженер | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү буенча лаборатория (бюро) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, инженер |
| 5. | Кадрлар бүлеге башлыгы (махсус бүлек һ. б.), кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер,табельче | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һәм башкалар) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер, инструктор-дактилолог, профконсультант, юрисконсульт, табельче |
| 6. | Социаль үсеш бүлеге башлыгы | Социаль үсеш бүлеге башлыгы, кадрлар бүлеге башлыгы, бүлек башлыгы |
| | | Кадрлар әзерләү, хезмәт өчен түләү һәм оештыру бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюро) башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар әзерләү буенча белгеч, инструктор-дактилолог, кадрлар буенча инспектор, хезмәтне саклау һәм техника буенча инженер, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, хезмәт буенча техник, социолог |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Профконсультант | Профконсультант, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, персонал буенча менеджер, психолог, социолог, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге инспекторы, инструктор-дактилолог |
| 8. | Инструктор-дактилолог | Инструктор-дактилолог,социаль үсеш бүлеге башлыгы, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюро) башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар әзерләү буенча инженер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, профконсультант , хезмәт буенча техник |
| 9. | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт |
| 10. | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документлар алып баручы, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту буенча инспектор, секретарь, секретарь-машинист, секретарь-стенографист, стенографист, күрмәүче белгеч секретаре, җитәкче секретаре, паспортист, кодификатор, экспедитор | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документовед, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту инспекторы, секретарь, секретарь-машинистка, секретарь-стенографистка, стенографистка, машинистка, күрмәүче белгеч секретаре, җитәкче секретаре, паспортист, кодификатор, экспедитор |
| 11. | Машинкада басу бюросы мөдире, күчермә-күбәйткеч бюро мөдире, машинистка | Машинкада басу бюросы мөдире, күчермә-күбәйткеч бюро мөдире, машинистка, секретарь-машинистка, күчермәче |
| 12. | Матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире, агент, сатып алулар буенча агент, тәэмин итү агенты, йөк ташу буенча экспедитор | Матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире, товар белгече, агент, сатып алулар буенча агент, тәэмин итү агенты, тәэмин итү буенча икътисадчы, йөкләр ташу буенча экспедитор |
| 13. | Пансионатның (кунакханәләрнең) торак | Пансионатның (кунакханәләрнең) торак корпусы мөдире, тулай торак |

| | | |
|---|---|---|
| | корпусы мөдире, тулай торак мөдире, пропусклар бюросы мөдире, пропускларның дежур бюросы, дежурный (белешмәләр бирү буенча, зал, кунакханәнең каты, автомобиль йөртүчеләрнең ял итү бүлмәсе, тулай торак һ. б.), комендант, администратор, саклау камерасы мөдире | мөдире, пропусклар бюросы мөдире, пропускларның дежур бюросы, дежурный (белешмәләр бирү буенча, зал, кунакханәнең каты, автомобиль йөртүчеләрнең ял итү бүлмәсе, тулай торак һ. б.), комендант, администратор, |
| 14. | Гараж башлыгы | Гараж башлыгы, автоколонна башлыгы, пассажир транспорты контролеры, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы, автотехник экспертиза буенча белгеч (эксперт-автотехник), юл хуҗалыгы эксперты, автотранспорт йөртүче |
| 15. | Җитештерү мөдире (шеф-повар), ашханә мөдире | Җитештерү мөдире (шеф-пешекче), ашханә мөдире, пешекче |
| 16. | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы |
| 17. | Фотолаборатория мөдире | Фотолаборатория мөдире, фотограф, рәссам-фотограф |
| 18. | Ремонт цехы башлыгы, остаханә башлыгы (мөдире), механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик) | Ремонт цехы башлыгы, остаханә башлыгы (мөдире), механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик), инженер |
| 19. | Инженер-программист (программист), техник-программист, математик, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты | Җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы бүлеге башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, инженер-программист (программист), җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру буенча инженер, җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системалары буенча инженер, инженер, математик, техник-программист, техник, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты |
| 20. | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни- |

| | | |
|---|---|---|
| | башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник | техник мәгълүмат бүлеге башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, патент һәм уйлап табу эше буенча инженер, инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник, техник |
| 21. | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик |
| 22. | Инженер | Барлык атамалар инженеры, җитештерү бүлеге башлыгы, техник бүлек башлыгы, тәҗрибә җитештерү цехы башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, цех (участок) башлыгы, капиталь төзелеш бүлеге башлыгы, участок мастеры, механик, техник, техник-конструктор, инструментлар буенча техник, техник-технолог |
